РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» март 2023 ел г. Альметьевск № 634

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының «Капиталь
төзелеш объектларын төзүгә
рөхсәт бирү тәртибен, объектны
файдалануга кертүгә рөхсәт бирү,
планлаштырылган төзелеш турында
хәбәр итү һәм төзелгән индивидуаль торак
төзелеше объектларына яисә бакча йортына
туры килү тәртибен раслау турында»
2021 елның 16 апрелендәге 552 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирү тәртибен, объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү, планлаштырылган төзелеш турында хәбәр итү һәм төзелгән индивидуаль торак төзелеше объектларына яисә бакча йортына туры килү тәртибен раслау турында» 2021 елның 16 апрелендәге 552 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 3 октябрендәге 2184 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарга 1 нче кушымтаның 2 бүлегендәге 2.5.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле егерме беренче абзац белән тулыландырырга:

«әгәр мондый килештерү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 статьясында каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелешен килештерү».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

Зак. № 305-2000

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов